ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
**БИЛГЕЛӘМӘСЕ**

**Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Казан шәһәренең торак фондында торак урыннарны карап тоту өчен, торак урыннарыннан файдалану өчен түләү (наем өчен түләү) күләме турында» 2018 елның 20 декабрендәге 6433 номерлы карарының 8 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.Н. Юсипова шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

Казан шәһәре 2019 елның 27 декабре

Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка Г.Н. Юсипова шикаятен алдан өйрәнгән судья Ф.Р. Волкова бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Г.Н. Юсипова Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Казан шәһәренең торак фондында торак урыннарны карап тоту өчен, торак урыннарыннан файдалану өчен түләү (наем өчен түләү) күләме турында» 2018 елның 20 декабрендәге 6433 номерлы карарының (алга таба шулай ук — Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карары) 8 пункты

белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карарының 8 пункты нигезендә күпфатирлы йортта торак урынны карап тоту өчен түләү күләме күрсәтелә торган хезмәтләрнең составына һәм күпфатирлы йортның конструктив үзенчәлекләренә карап исәпләнә һәм үзгәртелә.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документларның күчермәләреннән аңлашылганча, гражданка Г.Н. Юсипова андагы торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләме Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карары нигезендә билгеләнгән күпфатирлы йортта торак урынның милекчесе булып тора. Мөрәҗәгать итүче үзенең 1960 елда төзелгән йортта яшәвен, аның техник яктан канәгатьләнмәслек хәлдә булуын, физик яктан тузуын, шуңа бәйле рәвештә аңа үз билгеләнешенә туры килмәү ихтималы булган объектларны карап тоту өчен күбрәк түләргә туры килүен билгеләп үтә. Аның фикеренчә, дәгъва белдерелә торган норма Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту кагыйдәләренең (алга таба шулай ук — Кагыйдәләр) 11 пунктында билгеләнгән барлык критерийларны да үз эченә алмый, аның нигезендә гомуми мөлкәтне карап тоту хезмәтләре һәм эшләре гомуми мөлкәтнең составына, конструктив үзенчәлекләренә, физик тузу дәрәҗәсенә һәм техник торышына, шулай ук күпфатирлы йорт урнашкан җирнең геодезия һәм табигать-климат шартларына бәйле. Гражданка Г.Н. Юсипова күрсәткәнчә, шикаять белдерелә торган нигезләмә эчтәлегеннән күпфатирлы йортның конструктив үзенчәлекләре дигәндә нәрсә күз алдында тотылуы һәм аларның торак урынны карап тоту өчен түләүне исәпләүгә һәм үзгәртүгә ничек йогынты ясаулары аңлашылмый.

Торак йортның конструктив үзенчәлекләрен исәпкә алып түләү күләме кем тарафыннан исәпләнә һәм алар торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен арттыруга ничек йогынты ясый дигән мәсьәләдә билгесезлек күреп,

мөрәҗәгать итүче шуңа бәйле рәвештә идарәче компания торак урынны карап тоту өчен җирле үзидарә органнары тарафыннан инде билгеләнгән түләү күләмен үзгәртә ала дип саный.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданка Г.Н. Юсипова Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Казан шәһәренең торак фондында торак урыннарны карап тоту, торак урыннарыннан файдалану өчен түләү (наем өчен түләү) күләме турында» 2018 елның 20 декабрендәге 6433 номерлы карарының 8 пунктын Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 49 статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Россия Федерациясе Торак кодексының 39 статьясындагы 1 һәм 2 өлешләренең, шулай ук Кагыйдәләрнең 28 пунктының үзара бәйле нигезләмәләре буенча күпфатирлы йорттагы торак урыннар милекчеләре гомуми мөлкәтне карап тотуга чыгымнарны, әлеге мөлкәткә гомуми мөлкәт хокукындагы өлешләренә карап, күпфатирлы йорттагы торак урынны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләүне кертү юлы белән үз өсләренә алырга тиеш. Россия Федерациясе Торак кодексының 154 статьясындагы 2 өлешенең 1 пункты һәм 156 статьясындагы 1 өлеше нигезендә күрсәтелгән түләү күпфатирлы йорттагы торак урын милекчесе өчен торак урынга һәм коммуналь хезмәтләргә түләү структурасына керә һәм ул күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тотуны законнар таләпләре нигезендә тәэмин итә торган күләмдә билгеләнә.

Шул ук вакытта, гомуми кагыйдә буларак, күпфатирлы йортта торак урыннар милекчеләренә торак өлкәсендә бәя куюны җайга салуга өстенлекле хокукны беркетеп, әлеге Кодекс шулай ук күпфатирлы йортта торак урыннар милекчеләре тарафыннан тиешле ихтыяр белдерелмәвенә бәйле рәвештә аннан чыгарылмаларны да үз эченә ала. Россия Федерациясе Торак кодексының 158 статьясындагы 4 өлеше һәм Кагыйдәләрнең 36 пункты нигезендә күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре гомуми җыелышта торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул

итмәгән очракта, җирле үзидарә органнары күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре торак урынны карап тоту өчен кертә торган түләү күләмен күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми җыелышы карары белән расланган тиешле эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы затлар башкара торган хезмәтләр һәм эшләр исемлегенә кергән хезмәтләр һәм эшләр бәясеннән чыгып билгелиләр.

Шул рәвешле, шикаять белдерелә торган хокукый җайга салу үзенең хокукый табигате һәм асылы буенча күпфатирлы йортта торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләүнең альтернатив ысулы гына булып тора.

Татарстан Республикасы Конституция суды үзенең карарында торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләме күпфатирлы йортның конструктив үзенчәлекләренә генә түгел, зуррак юридик көчкә ия булган акт нигезендә билгеләнгән башка параметрларга да бәйле рәвештә исәпләнергә һәм үзгәртелергә тиешлегенә игътибар юнәлткән иде инде. Әлеге алым бу түләү күләмен милекчеләр үзләре билгеләгәндә дә, мондый түләүнең җирле үзидарә органнары тарафыннан расланган күләмен исәпләгәндә һәм үзгәрткәндә дә исәпкә алынырга тиеш (2017 елның 21 ноябрендәге 76-П номерлы карар).

Дәгъва белдерелә торган муниципаль норматив хокукый акт Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына бирелгән вәкаләтләр чикләрендә, федераль законнарның югарыда күрсәтелгән нигезләмәләренә таянып кабул ителгән һәм милекчеләрнең гомуми җыелышларында күпфатирлы йортлардагы торак урыннар милекчеләренең карар кабул итү, шул исәптән күпфатирлы йортта торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү буенча да, хокукын гамәлгә ашыруда чикләүләр юк.

Шулай итеп, шикаять белдерелә торган норматив нигезләмәдә аның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве турындагы мәсьәләдә билгесезлек юк, шуңа бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты белән үзара бәйләнештә

46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүченең шикаяте карала алмый.

Дәгъва белдерелә торган актның конституциячел булмавын нигезләү буларак гражданка Г.Н. Юсипова китергән дәлилләр аның үзенең конституциячел хокуклары бозылуны муниципаль актның норматив нигезләмәләре эчтәлегенә түгел, бәлки гамәлләренә (гамәл кылмавына) бәя бирү, Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясында һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясында билгеләнгәнчә, Татарстан Республикасы Конституция суды компетенциясенә керми торган идарәче оешма тарафыннан күпфатирлы йортта торак урынны карап тоту өчен түләүне иректе исәпләү мөмкинлеге белән бәйләп каравын күрсәтә.

Бәян ителгәннәр нигезендә һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 2 пунктларына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Казан шәһәренең торак фондында торак урыннарны карап тоту өчен, торак урыннарыннан файдалану өчен түләү (наем өчен түләү) күләме турында» 2018 елның 20 декабрендәге 6433 номерлы карарының 8 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.Н. Юсипова шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки ул «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законы билгеләгән таләпләр нигезендә карала алмый, ә мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләләрне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

2. Әлеге шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка Г.Н. Юсиповага һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) басылып чыгарга тиеш.

**№ 42-О**

**Татарстан Республикасы**
**Конституция суды**